**СОВЕТ АКБУРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Октябрьская, д. 44,
с. Акбуре, 423197

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБҮРЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Октябрь урамы,44 нче йорт
Акбүре авылы, 423197

тел.: (8-84348) 3-62-40, факс: (8-84348)3-62-40, Akbur.Nsm@tatar.ru

Акбуре авыл җирлеге советы утырышы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
КАРАРЫ

2021 елның 29 марты № 9-22

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге Советының 16.03.2020 елнын № 66-131 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы кодексы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге Советының 10.04.2020 елнын № 67-135 карары(2020 елның 15 июнендәге 69-142 номерлы карар редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләр кертергә:

1.1. 7.3 пунктның 4 һәм 6 пунктчалары түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

1.2. 16.3 пунктының унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

1.3. 24.4 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
2) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, шулай ук кирәк булганда, муниципаль хезмәт стажынраслый торган һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 30 статьясында күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;;»;
түбәндәге эчтәлекле җиденче һәм сигезенче абзацлар өстәргә::
"Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затта Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда башкарыла.
Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү шундый билгеләнеш сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.»;
1.4. 25.2 статьяның ундүртенче абзацында. «хезмәт кенәгәсенә "сүзләреннән соң" “(булганда)”;
1.5. 30 бүлекне төшереп калдырырга;
1.6. № 1 һәм № 2 кушымталарны төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" бастырырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (novosheshminsk.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акбуре авыл җирлеге башлыгы Ж.М.Җәләлетдинов